ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 3-11-18, факс: (84379) 3-11-18.

10.12.2020 № 4

На № ______________ от ________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Восточная Звезда авылында халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1нче, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Восточная Звезда авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 3200 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза буласызмы?: дигән сорау буенча 2020нче елның 10нчы декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

- балалар мәйданчыгын төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 9 кеше, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан 8 кеше кертелгән. Җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 8 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Восточная Звезда авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Восточная Звезда авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2021нче елда 3200 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә  риза буласызмы?: дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре  буенча карарны таныргa:

- балалар мәйданчыгын төзекләндерү.

3. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Восточная Звезда авылында  узган халык җыенының нәтиҗәләрен Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларын теркәү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгына  җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Д. В. Морозов